«РАСЛЫЙМ»
ДБО «К. Тинчурин исемендәге
ТДДһК театры» директоры

_____ Ф.Н. Мөсәгыйтов

«__» _____ 2024 ел

Дәүләт бюджет оешмасы
«К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры»на йөрү, билетларны сату һәм кире кайтару кагыйдәләре

1. Гомуми нигезләмә

1.1. Әлеге Кагыйдәләр Россия Федерациясенең «Кулланучыларның хокукын яклау турында»гы 1992 елның 7 февралендә дөнья күргән 23 00-1 санлы Федераль законга, Россия Федерациясенең Гражданлык кодексына, «Терроризмга каршы тору турында» 2006 елның 6 мартындагы 35-ФЗ номерлы Законга, «Янгын куркынычсызлыгы турында» 1994 елның 21 декабрендәге 69 номерлы Федераль законга, «Әйләнә-тирәдәге тәмәке төтене йогынтысыннан һәм тәмәке куллану нәтиҗәләреннән гражданнарның сәламәтлеген саклау турында» 2013 елның 23 февралендәге 15-ФЗ номерлы Федераль законга, «Этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм аларның әйләнешен дәүләт җайга салуы турында һәм алкоголь продукциясен куллануны (эчүне) чикләү хакында» 1995 елның 22 ноябрендәге 17-ФЗ номерлы Федераль законга, Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына, «Балаларны аларның сәламәтлегенә һәм үсешенә зыян китерә торган мәгълүматтан яклау турында» 2010 елның 29 декабрендәге 436-ФЗ номерлы Федераль законга, «Мәдәният турында Россия Федерациясе законнары нигезләре» Россия Федерациясенең 1992 елның 9 октябрендәге 3612-1 номерлы законына, «Мәдәният турында Россия Федерациясе законнары нигезләре «Россия Федерациясе Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 18 июлендәге 193-ФЗ номерлы РФ Федераль законына, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «билетларны, абонементларны һәм экскурсия юлламаларын кире кайтару һәм башка затларга башкару сәнгате оешмалары һәм музейлар тарафыннан үткәрелә торган тамаша чараларына исемле билетларны, исемле абонементларны һәм исемле экскурсия юлламаларын кире рәсмиләштерү кагыйдәләрен һәм шартларын раслау турында»гы 2020 елның 18 сентябрендәге 1491 номерлы карары, Дәүләт бюджет оешмасы «К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры» Уставына (алда - Театр) нигезләнеп эшләнде һәм ул Театр тарафыннан үткәрелүче спектакльләргә, концертларга, тамашаларга, иҗат кичәләренә, фестивальләргә, конкурсларга (алда - чаралар) билетлар сату һәм билетларны кире кайтаруны, шулай ук Театрда узучы чараларга йөрү кагыйдәләрен регламентлаштыра.

1.2. Әлеге Кагыйдәләр учреждение бинасына һәм территориясенә кергәндә Театр һәм тамашачы арасында барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала.

1.3. Әлеге Кагыйдәләр Театр бинасында һәм территориясендә булганда тамашачының хокукларын һәм бурычларын, шулай ук аларга карата гамәлдә булган тыюларны һәм чикләүләрне билгели.

1.4. Әлеге Кагыйдәләр Казан шәһәре, Татарстан урамы, 1 йорт адресы буенча урнашкан театр бинасында һәм аның территориясендә гамәлдә.

1.5. Әлеге Кагыйдәләрнең гамәлдә булуы сыйфатлы хезмәт күрсәтүне оештыруга, тамашачының, шулай ук Учреждение хезмәткәрләренең мәнфәгатьләрен үтәүгә һәм иминлеген тәэмин итүгә юнәлдерелгән.

1.6. Әлеге кагыйдәләрне бозу һәм/яки аларны гамәлгә ашыруга комачаулау гаепле затларга карата гамәлдәге законнар нигезендә дисциплинар, административ, гражданлык-хокукый, җинаять җаваплылыгы чараларына китерә. Әлеге Кагыйдәләрне үтәмәгән тамашачылар Учреждение бинасыннан чыгарылырга мөмкин, шул ук вакытта сатып алынган билетларның бәясе кире кайтарылмый.

1.7. Театр администрациясе Театр чараларының актерлар составына алдан хәбәр итмичә генә үзгәрешләр кертү хокукын үзендә калдыра.

2. Театр билетларын сату тәртибе

2.1. Тамашачы чараларга билетларны театр кассасында, театрның рәсми сайтында, граждан-хокук шартнамәсе нигезендә эш итүче вәкаләтле затлардан, рәсми вәкилләрдән сатып ала ала.

2.2. Конкрет көнгә һәм билгеле бер чарага билетларның булу-булмавын тамашачы Театр кассасы яки Театрның рәсми сайты аша белә ала.

2.3. Билет сатып алганда тамашачы театраль куелыш, льготалар, Театрга йөрү кагыйдәләре турында тулы мәгълүмат алырга хокуклы.

2.4. Театр үткәрүче чарага билет алу белән сатып алучы сәнгать өлкәсендә башкаручы белән (Театр) хезмәт күрсәтү буенча килешү төзелү, шулай ук әлеге Кагыйдәләр белән килешү фактын раслый. Хезмәт күрсәтү буенча килешү төзелү сатып алучыга билет бирелү белән рәсмиләштерелә. Билет ул кулланучы белән төзелгән килешүнең шартлары турындагы мәгълүматны үз эченә алган билгеле бер кабул ителгән документ төре.

Билет үз эченә:

а) хезмәт күрсәтүнең исемен һәм төрен;

б) хезмәт күрсәтүнең вакытын (үткәрелүче чараның вакытын);

в) чараның үткәрелү урынын, шулай ук тамашачының тамаша залындагы урынын;

г) хезмәт күрсәтүнең бәясен,

һәм Россия Федерациясе законнар җыелмасына ярашлы башка мәгълүматларны ала.

2.5. Электрон билетлар театрның рәсми сайты (https://tinchurinteatr.ru/ru/), шулай ук https://www.ticketland.ru/, https://www.kassir.ru/, https:z7afisha.yandex.ru /kazan сайтлары аша сатыла.

2.6. Әгәр тамашачы билетны чит сайтта яисә башка ысул белән сатып алган булса, бу очракта Театр җаваплы булмый. Шуңа күрә керү билеты билгеләнгән үрнәктәге керү билеты, билгеләнгән үрнәктәге электрон билет яки билгеләнгән үрнәктәге чакыру билеты булып тормый.

3. Театр билетларын кире кайтару тәртибе

3.1. «Мәдәният турында Россия Федерациясе законнары нигезләре» 1992 елның 9 октябрендәге 3612-1 номерлы Россия Федерациясе Законы нигезендә, әлеге Кагыйдәләргә таянып, тамашачы театрга бәйле булмаган сәбәпләр аркасында театрга барудан баш тарткан очракта, тамашачы билетны кире кайтару хокукына ия, акчаларны кире кайтару суммасы түбәндәге тәртиптә исәпләнә:

— тамашага килүче чарага килүдән уздыру көненә кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча баш тарткан очракта билет бәясенең 100% ты кире кайтарыла.

10 көннән дә кимрәк, әмма 5 көннән дә соңга калмыйча мөрәҗәгать ителгән очракта билет бәясенең 50% ы кире кайтарыла.

— 5 көннән дә кимрәк, әмма 3 көннән дә соңга калмыйча мөрәҗәгать ителгән очракта билет бәясенең 30% ы кире кайтарыла.

— 3 көннән дә кимрәк вакытта мөрәҗәгать ителгән очракта билет бәясе кире кайтарылмый.

3.2. Театр саткан билетны Тамашачының авыруы йә аның гаилә әгъзасы яки якын туганы булган затның вафат булуы сәбәпле кире кайтару, Чара уздырылган көннән дә соңга калмыйча мөрәҗәгать ителгән очракта, гариза һәм раслаучы документлар нигезендә 100% күләмендә гамәлгә ашырыла.

3.3. Бары тик театр кассасы яки граждан-хокук шартнамәсе килешүе нигезендә эш итүче вәкаләтле затлар аша сатып алынган билетлар гына кире кайтарыла.

Бары Театр кассасыннан сатып алынган, касса чегы булган оригинал билетлар гына кире кайтарыла һәм алыштырыла.

3.4. Гаризаны карау вакыты гариза кабул ителгән көннән алып 10 көннән дә артмый. Учреждение файдаланылмаган билет өчен акчаларны кире кайтару, яисә акчаларны кире кайтарудан баш тарту турында Карар кабул итә һәм бу хакта килүчегә (аның вәкиленә) хәбәр итә.

3.5. Акчаларны кире кайтару яисә кире кагу турында кабул ителгән карар турында Учреждение, я вәкаләтле зат, карар кабул ителгән көннән алып 5 көннән

дә соңга калмыйча, мөрәҗәгать итүчегә яисә аның вәкиленә түбәндәге ысул белән хәбәр итә:

- хәбәрнамәнең күчермәсен электрон почта адресына яисә кире кайтару турындагы гаризада күрсәтелгән телефон аша җибәрә.

3.6. Чара алмаштырылган, гамәлдән чыгарылган яки күчерелгән очракларда тапшырылучы билетлар бәясе сатып алучыга тулысынча кайтарыла (100%).

3.7. Билетлар түбәндәге сорокларда кабул ителә:

- чара алмаштырылуы турында рәсми хәбәр ителгәннән алып алмаштырылган чара башланганчыга кадәр;
- чараны күчерү турында рәсми хәбәр ителгәннән соң;
- чараны гамәлдән чыгарганда - чараны гамәлдән чыгару турында рәсми хәбәр ителгәннән алып билетта күрсәтелгән датага кадәр.

3.6. Барлык очракларда да билетлар сатып алучының гаризасы нигезендә һәм шәхесне таныклаучы документ - паспорт булганда кабул ителә.

3.7. Сатып алучы кире кайтарган Чара билетларын Театр кабат сатарга хокуклы.

3.8. Чара алмаштырылган очракта театр кассасыннан яисә театр исеменнән граждан-хокук шартнамәсе нигезендә эш итүче вәкаләтле затлар аша сатып алынган билетлар гамәлдә дип санала һәм сатып алучының теләге буенча алмаштырылган чарага алыштырыла ала.

3.9. Театр администрациясе ялган билетлар һәм Театрның рәсми вәкилләре булмаган затлардан алынган билетлар өчен җаваплы түгел.

3.10. Кулланылмаган театр билеты башка спектакльләргә керү хокукын бирми.

3.11. Буш урыннар булганда һәм билет бәясе элек сатылган билет бәясенә, ә сроклар билетларны кире кайтару кагыйдәләренә туры килсә, Администрация рөхсәте белән билетны башка чарага алмаштыру рөхсәт ителә.

3.12. Ташлама белән сатылган билетлар бәясен кире кайтару гамәлдән чыгарылган, күчерелгән яисә алмаштырылган чаралар буенча алынган ташламаларны исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

3.13. Театр кассасыннан сатып алынган кәгазьдәге билет, ул югалган (зыян күргән) очракта, теләсә нинди сәбәп аркасында яңартылмый һәм кире кайтарылмый.

4. Чараларга йөрү тәртибе

4.1. Учреждение мөстәкыйль рәвештә эш режимын билгели. Учреждениедә тамашачыларга керү чара башланганчы 1 (бер) сәгатьтән дә иртәрәк гамәлгә ашырылмый.

4.2. Тамаша залына бары беренче кыңгыраудан соң керү рөхсәт ителә. Өченче (соңгы) кыңгыраудан соң тамаша залына керү билетлар контролеры яки Театр администрациясе рөхсәте белән башкарыла.

4.3. Спектакль башланырга биш минут соңга калган тамашачы залга тәнәфес вакытында гына үтәргә мөмкин.

4.4. Өченче кыңгыраудан соң тамашачы, тәнәфескә кадәр, театрдан билетта күрсәтелгән урынын таләп итә алмый.

4.5. Тамашачыларга спектакль барышында залда йөрү тыела.

4.6. Тамашачы Театр милкенә сак караргa тиеш. Театр милкенә материаль зарар китергән очракларда, РФ законнар җыелмасы нигезендә, ул зыянны тулысынча түләргә бурычлы.

4.7. Чарага керү хокукын бирә торган документ булып Театр бинасына кергәндә күрсәтелә торган тиешле үрнәктәге керү билеты, тиешле үрнәктәге электрон билет йә тиешле үрнәктәге чакыру билеты тора. Тамашачы тамаша залында сатып алынган билетта (электрон билет, чакыру билеты) күрсәтелгән урынга гына утыра.

4.8. Бер билет бары бер кеше өчен генә театрга керү хокукын бирә, һәр билет тамашачыга бары тик анда күрсәтелгән вакытта һәм датада булачак чарага гына керү хокукы бирә.

Театрга килгән барлык тамашачыларның да, нинди яшьтә булуларына карамастан, шул исәптән балалар өчен үткәрелгән чараларга килүчеләрнең дә һәрберсенең аерым билеты булырга тиеш.

4.9. Балаларны озата йөрүче затлар балалар өчен чараны сайлауга игътибарлы булырга һәм чарага йөрү өчен яшь чикләүләрен исәпкә алырга тиеш. Бу чакта чарага килгәндә яшь категориясен үтәү өчен баланы озата йөрүче зат җаваплы була.

4.10. Тамашачыларның театрга керүен контрольдә тотуның автоматлаштырылган системасын кулланып башкарыла.

4.11. Электрон билет бастырылган яки электрон рәвештә, шул исәптән QR — кодны (штрих-кодны) укырга мөмкинлек бирә торган скрин-күчермә рәвешендә электрон җайланмада сакланган сурәт рәвешендә күрсәтелергә тиеш. Учреждение кәрәзле элемтә булмаганда QR-кодны (штрих-кодны) укый алмау өчен җаваплы түгел.

4.12. Электрон билетларны күчереп алган очракта, чарага керү билеты һәм аны түләү турындагы документлары булган затка керү өстенлеге бирелә.

4.13. Билетны сатып алганда, Тамашачы билетларны сатуның билгеләнгән кагыйдәләрен һәм әлеге Кагыйдәләрне үтәү бурычын үз өстенә ала.

4.14. Билет Кагыйдәләрнең 2.1., 2.5. п. күрсәтелгән урыннарда түгел, ә башка урыннарда сатып алган очракта, Гражданин билетның чынлыгына бәйле барлык куркынычларны да үз өстенә ала.

4.15. Төркем белән учреждениегә кергәндә төркем җитәкчесе керү билетларын затлар саны буенча тапшыра, контролер чакырганнан соң төркемне чиратлап алга җибәрә һәм, аны йомгаклап, үзе уза.

4.16. Хәрәкәт итүе чикләнгән һәм/яки мөстәкыйль хәрәкәт иткәндә кыенлыклар кичергән тамашачыларга, шулай ук сәламәтлеге торышы буенча мөмкинлекләре чикләнгән башка тамашачыларга һәм аларны озата йөрүчеләргә махсус урыннар бирелә (булган очракта), махсус урын алу өчен югарыда күрсәтелгән затлар ташламалы билет сатып алганда бу хакта кассирга хәбәр
итәргә тиеш. Мөмкинлекләре чикләнгән тамашачылар өчен билетлар Театр кассасына турыдан-туры мөрәҗәгать иткән саен чират тәртибендә гамәлгә ашырыла.

Махсус урыннарга ташламалы билет 14 яшькә җитмәгән инвалид балаларга һәм бер озата баручы затка сатыла. Билетны ташламалы бәядән сатып алу өчен Театр кассасында раслаучы документларны күрсәтергә кирәк (белешмә, РФ Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының 2010 елның 24 ноябрендәге 1031н номерлы боерыгына 1 нче кушымта формасы буенча).

Театр кассиры буш урыннар булмаган очракта билетны ташламалы бәядән

сатудан баш тартырга хокуклы.

Тамашачылар ярдәм алу өчен чара башланыр алдыннан җаваплы затка мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Объектта ситуацион ярдәм күрсәтү, хезмәт күрсәтү һәм инвалидларга һәм халыкның хәрәкәте чикләнгән башка төркемнәренә ярдәм күрсәтү өчен җаваплы затлар булып түбәндәгеләр санала: Өлкән администратор.

4.17. Куркынычсызлык максатларында:

—Учреждениегә керү металл эзләгеч рамкасы аша, сак хезмәткәрләре катнашында башкарыла. Сак хезмәткәре таләбе буенча рамка сигналы булган очракта, тамашачылар Учреждение бинасына тыелган предметларны кертүне ачыклау һәм булдырмау максатыннан шәхси әйберләрен визуаль карау өчен кул йөген күрсәтәләр.

—Учреждение бинасында видеокүзәтү алып барыла.

—Учреждение бинасына исерек, наркотик яки токсик хәлдәге тамашачылар, шулай ук үз-үзләрен дөрес тотмаган, агрессив, психик яктан адекват булмаган тамашачылар кертелми. Администратор (өлкән администратор) театрга чарага тамашачыларны, аларда ачыктан-ачык исереклек билгеләре булганда, хокук саклау органнарына кичекмәстән хәбәр итеп, шулай ук киләчәктә мондый затларны театр бинасына кертмәү турында акт төзеп, кертмәскә хокуклы. Театр хезмәткәрләре әлеге Кагыйдәләрне Тамашачылар тарафыннан тупас бозуларны документаль рәвештә теркәү хокукында. Әлеге кагыйдәләрне, җәмәгать урыннарыда үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен, этика кагыйдәләрен, янгын куркынычсызлыгы һәм хезмәтне саклау кагыйдәләрен бозган тамашачылар театрдан чыгарып җибәрелергә мөмкин. Әлеге пунктта күрсәтелгән сәбәпләр аркасында тамашачыларны тамаша вакытында спектакльгә кертү чикләнгән яки театр бинасыннан куып чыгарылган очракта, билет бәясе кире кайтарылмый.

Учреждение бинасына тамашачылар роликлы тимераякта, велосипедлар, самокатлар һәм башка төр спорт инвентарьлары, шулай ук хайваннар белән кертелми.

— тамашачыларга һәм театрга килүчеләргә учреждениегә теләсә нинди корал, наркотик матдәләр һәм аларны куллану өчен җайланмалар, психотроп чаралар, очлы һәм үткен предметлар, үз-үзеңне саклау өчен махсус чаралар, тиз янучан, шартлагыч, агулы, исле, радиоактив матдәләр, пиротехник эшләнмәләр, эре габаритлы, пычрак, пычраткыч предметлар, шулай ук пыяла предметлар (шешәләр, тәлинкәләр һ.б.) белән керү тыела.

— балалар коляскалары белән тамаша залына керү (инвалидлар өчен коляскалардан тыш) тыела.

5. Гардеробтан файдалану кагыйдәләре

5.1. Учреждение гардеробы түбәндәге режимда эшли:

— эш башлану — чара башланырга бер сәгать кала

— эшне тәмамлау - чара тәмамланганнан соң 30 минуттан.

5.2. Әйберләрне гардеробка саклауга кабул итү жетон бирү белән раслана. Бер заттан кабул ителгән әйберләргә бер жетон бирелә.

5.3. Әйберләр жетон күрсәтүчегә бирелә, шул ук вакытта гардероб хезмәткәре жетон күрсәтүченең саклауга тапшырылган әйберләрне алу хокукын тикшерергә тиеш

түгел.

5.4. Жетон югалган очракта тамашачы бу хакта кичекмәстән өлкән администраторга хәбәр итәргә тиеш.

Әйберләрне кире кайтару 1 нче кат фойесында әйберләрнең тышкы кыяфәте һәм үзенчәлекләре тасвирланган язма гариза буенча, әйберләргә дәгъва кылучының шәхесен таныклаучы документы булганда гамәлгә ашырыла һәм тиешле акт белән, тамашачы һәм Учреждение вәкиле (өлкән администратор) тарафыннан имзалану юлы белән теркәлә.

5.5. Гардеробта онытылган һәм чара тәмамланганнан соң кирәк булмаган әйберләр өлкән администратор катнашында тикшерелергә һәм махсус билгеләнгән урынга саклауга тапшырыла. Саклауга тапшырылганнан соң өч календарь ай эчендә таләп ителмәгән әйберләр утильләштерелә.

5.6. Учреждение җаваплы түгел:

—кием кесәләре һәм гардеробка тапшырылган сумкалар, кейслар һәм пакетлар эчендәге әйберләр өчен;

—саклауга тапшырылган әйберләргә вак-төяк зыян килгән өчен (элгечләр, төймәләр өзелү);

—тамашачы гардеробка үзе элеп куйган (калдырган) әйберләр өчен;

— ябылудан соң гардеробта калдырылган әйберләрнең сакланышы өчен.

5.7. Гардеробка саклауга алынмыйлар:

— акча, документлар, кәрәзле телефоннар һәм башка кыйммәтле әйберләр;

— зур габаритлы (25х40 см дан зуррак) һәм авырлыгы 5 кг дан артык булган әйберләр;

— азык-төлек, чаналар, чаңгылар, музыка кораллары, сумкалар, арбалар, велосипедлар, самокатлар һ. б.;

— пычрак әйберләр;

—химик әйберләр һәм дарулар.

5.8. Тамашачыларга тыела:

—билгесез затлардан әйберләрне алга таба гардеробка тапшыру өчен алырга;

—гардеробка керергә һәм мөстәкыйль рәвештә кием элергә яки шәхси әйберләрне урнаштырырга;

—саклауга тапшырылган әйберләрне мөстәкыйль алырга;

—жетон югалган очракта, Учреждение тамашачы мөлкәтен саклау өчен җаваплылык тотмый;

—жетонны югалткан (яки яраксыз хәлгә китергән) өчен гражданин Учреждениегә 500 сум күләмендә акча түләргә тиеш.

6. Якларның хокуклары һәм бурычлары

6.1. Тамашачының хокуклары һәм бурычлары

6.1.1. Тамашачы бурычлы:

— чарага кергәндә контролерга керү билетын (чакыру билетын) күрсәтергә һәм билетта күрсәтелгән урынга утырырга;

— чара ахырына кадәр керү билетын (чакыру билетын) сакларга һәм аны тамаша залы хезмәткәре таләбе буенча күрсәтергә;

—әлеге кагыйдәләрне, җәмәгать урыннарында гражданнарның үз-үзләрен тотышының гомум кабул ителгән нормаларын, учреждение бинасында һәм Территориясендә тәртипне һәм чисталыкны үтәргә, учреждение администрациясенең һәм хезмәткәрләренең әлеге Кагыйдәләрдә беркетелгән законлы таләпләрен үтәргә;

— тамашачыларга, хезмәт күрсәтүче персоналга, тәртип саклау өчен җаваплы затларга ихтирамлы мөнәсәбәт күрсәтергә, әйләнә-тирәдәгеләр өчен комачаулык һәм куркыныч тудыра торган гамәлләргә юл куймаска;

— җәмәгать тәртибен саклау һәм янгынга каршы куркынычсызлык кагыйдәләрен үтәргә, шикле әйберләр, төтен һәм янгын чыгу билгеләренә тап булганда учреждение яки сак хезмәткәрләренә кичекмәстән хәбәр итәргә;

— эвакуация үткәрү турында мәгълүмат алганда, тамашачы кичекмәстән бинадан эвакуация планы нигезендә чыгарга, учреждениенең җаваплы затлары һәм дәүләт хезмәтләре хезмәткәрләре күрсәтмәләре буенча эш итәргә, тынычлык сакларга һәм паника тудырмаска тиеш;

— чаралар вакытында тамашачының мобиль һәм радиоэлектрон җайланмалары тавышсыз режимда булырга тиеш. Мондый җайланмаларны чара вакытында куллану тыела;

—чара тәмамланганнан соң тамашачы 15 минут эчендә залдан чыгып, бинадан чыгу юлына юнәлергә тиеш. Чара тәмамланганнан соң тамашачыга учреждение бинасында булу рөхсәт ителми.

6.1.2. Тамашачыга тыела:

—учреждение хезмәткәрләренә һәм чараларны тәэмин итүче затларга коррупцион, үтәлмәслек яки әдәпсез характердагы тәкъдимнәр ясарга, аларны сүзләр яки гамәлләр белән кимсетергә, үз хезмәт бурычларын үтәүдә игътибарларын читкә юнәлтергә;

— чараларга керү билетыннан башка керергә;

—14 яшьтән кечерәк булган балаларны караусыз калдырырга;

— учреждение территориясендә һәм бинасында тәмәке тартырга;

—Учреждение мөлкәтен бозарга, язулар язарга, төрле әйберләрне (төргәкләрне, сагызларны, шешәләрне, азык-төлек калдыкларын һ.б.) чүпләргә һәм ташларга;

—тамаша залына өске киемнән керергә, үзең белән алкогольле эчемлекләр, пиротехник чаралар һәм лазер җайланмалары алып килергә;

— авторлык хокукы иясенең махсус рөхсәтеннән башка алга таба тарату һәм/яки коммерцияле файдалану максатларында кино - видео - һәм фотога төшерергә;

— бинадан Учреждениенең матди кыйммәтләрен, җиһазларын һәм башка мөлкәтен алып чыгарга;

— листовкалар урнаштырырга, белдерүләр, плакатлар ябыштырырга һәм реклама-мәгълүмати эчтәлекле башка продукция таратырга;

— учреждение территориясеннән һәм бинасыннан коммерция, реклама яисә башка эшчәнлек белән шөгыльләнү өчен файдаланырга;

— тамаша вакытында лазер күрсәткечләреннән файдаланырга;

— гамәлдәге законнар нигезендә мондый эшчәнлекне алып бару мөмкинлеген бирә торган чаралар уздырылган очраклардан кала учреждение территориясендә һәм биналарында теләсә нинди агитация эшчәнлеген гамәлгә ашырырга;

— алкоголь, наркотик яисә токсик исерек хәлдә театр бинасына һәм территориясенә керергә.

6.1.3. Тамашачының хокукы бар:

— хезмәткәрләрдән чарага кагылышлы мәгълүмат сорарга һәм белешмә алырга;

— хезмәт күрсәтү сыйфаты мәсьәләләре буенча һәм белешмә мәгълүмат алу өчен театр администрациясенә мөрәҗәгать итәргә;

— гардеробтан, буфеттан Учреждение яисә чараларны оештыручылар тарафыннан күрсәтелә торган башка хезмәтләрдән билгеләнгән тәртиптә файдаланырга;

6.1.4. Учреждение бинасында уздырыла торган чарага килүе белән тамашачы учреждение хезмәткәрләре, учреждение бинасында килешүләр нигезендә фото-һәм видео төшерүче затларга тышкы кыяфәтләрен фотога, видеога төшерүнең барлык төрләренә ризалык (рөхсәт) бирә, шулай ук мондый фото - һәм видеоматериалларны халык алдында файдалана ала.

6.2. . Учреждениенең хокуклары һәм бурычлары

6.2.1. Учреждение бурычлы:

— тамашачыга ул сатып алган билет (чакыру билеты) нигезендә урын белән тәэмин итәргә;

— чараны үткәрү вакытына гардеробка саклауга алынган өске киемнең сакланышын тәэмин итәргә;

— тамашачыларга чараны үткәрү урыны, башлану вакыты, билет бәяләре, чарага килүгә яшь чикләүләре турында мәгълүмат бирергә;

6.2.2. Учреждение (учреждениенең җаваплы хезмәткәрләре) хокуклы:

— чаралар үткәрү вакытын үзгәртергә, спектакльләрне һәм (яисә) актерлар составын алыштырырга;

— театрга хайваннар белән килгән тамашачыларны чарага кертмәскә;

— хокук бозучыларга телдән кисәтүләр ясарга (коррект формада), әлеге кагыйдәләрне тупас бозуларны документаль рәвештә теркәргә, шулай ук конфликтлы хәлләрне хәл итү өчен сак хезмәткәрләрен һәм хокук саклау органнары хезмәткәрләрен җәлеп итәргә;

— җәмәгать тәртибен бозучы тамашачыларны чара башланганчы һәм чара вакытында театр бинасыннан һәм территориясеннән билет бәясен компенсацияләмичә чыгарырга.

7. Башка шартлар

7.1. Әлеге кагыйдәләр имзаланган вакыттан гамәлгә керә.

7.2. Спектакль Театрның һәм иҗат төркеменең интеллектуаль милке санала. Авторлык хокукларын яклау максатыннан Театр администрациясенең язмача рөхсәтеннән башка спектакльне видеога-, кинога-, фотога төшерү, аудиога яздыру тыела.

7.3. Театрда тамашачылар җәмәгать урынында тәртип сакларга, театраль этикет һәм янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен үтәргә тиешләр.

7.4. Тамашачылар спектакль күрсәтүне оештыру, кулланучылар белән үзара бәйләнеш регламентын булдыруга бәйле барлык мәсьәләләр буенча да тамашачылар буенча директор урынбасарына, дежур администраторга яки **8 (843) 293-14-24** телефоны аша шалтырата алалар.